Бажуковский филиал  Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение
«Усть – Туркская средняя общеобразовательная школа»

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| --- | --- | --- |
| Руководитель ШМО | Заместитель директора по УВР | Директор МАОУ «Усть-Туркская СОШ» |
| _____/ Муртазина | _____/ Аитова Э.Р. | _____/ Юсупова И.Ф. |
| Протокол №1 от «31» августа 2023 г. | «31» августа 2023 г. | Приказ №100 от «31» августа 2023 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА
# ПО РОДНОМУ ЯЗЫКУ
# ДЛЯ ОБУЧАЮЩИХСЯ 8 КЛАССА
# ЗАДЕРЖКОЙ УМСТВЕННОГО РАЗВИТИЯ

Составитель :

учитель татарского языка и литературы

Шавалиева З.А.

с.Бажуки, 2023

## Аңлатма язуы

Бүгенге җәмгыять зур үзгәрешләр кичерә, шуның белән бәйле татар телен укытуга да яңа таләпләр куела. Татар теле дәресләре белем бирүгә, җәмгыятькә һәм мәдәниятә мөнәсәбәтле максатларны тормышка ашыра. Бүген укучыларда уңышлы аралашу сәләте, кара-каршы сөйләшү осталыгы, монолог төзи белү, гомуми культура күрсәткече булган грамоталы язу кебек күнекмәләр формалаштыру зарур. Укучыларны тел фәненең төп тәгълиматлары белән таныштырып, шулар нигезендә аларның тамга-символик һәм логик фикерләвен, иҗади хыялын үстерү, татар теленең башка телләр белән берлектә дөньяның фәнни картинасын тудыруда катнашуы, милләтне саклап калуда, халыкның, шәхеснең үзенчәлеген югалтмауда ышанычлы нигез булуын аңлаулары бик мөһим. Әлеге таләпләр уку-укыту методикасын яңартуны, белем бирүгә яңача якын килүне, уку эшчәнлеген инновацион педагогик технологияләргә нигезләнеп оештыру бурычын куя.

Татар теленнән төп гомуми белем бирүнең **максатлары:**

- укучыларның башлангыч мәктәптә татар теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү;
- укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;
- телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү;
- татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзалларга, аларны тиешенчә куллана белергә өйрәтү;
- телнең милли әдәбиятыбызның чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату, татар теленең милли-мәдәни үзенчәлегенә төшендерү, татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү;
- текст һәм интернет, электрон уку-укыту ресурслары, башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм шуны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;
- укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

## Укыту предметына гомуми аңлатма

Федераль дәүләт стандарты куйган таләпләрнең иң мөһиме – укытучы һәм укучы арасындагы эшчәнлекне (деятельный характер образования) дөрес итеп оештыра алуга ирешү: укытучы – S, укучылар – ss = S ↔ ss , ягъни укучылар белем алырга килә, ә укытучы уку процессын оештыра һәм аларга ярдәм итә.

Татар телен укытканда, махсус белем һәм күнекмәләр камиллеген тәэмин итүгә юнәлтелгән универсаль гамәлләр формалаштыру зур әһәмияткә ия. Укучыларга танып-белүгә этәргеч бирү, уку эшчәнлегендә мөстәкыйльлек, иҗатка омтылыш тәрбияләү, хезмәттәшлекне оештыра, эшне планлаштыра белү, уку хезмәтендә максат ( уку мәсьәләсен – УМ ) куя алу, аңа ирешү өчен этапара бурычлар билгеләү һәм аларга ирешү өстендә (адымлап биремнәр үтәү аша) эшләү осталыгы булдыру бик мөһим. Иң беренче чиратта, бала белгәнен әле үзенә билгеле булмаганнан аера белергә, шуннан чыгып, танып белү максатын ( УМ ) мөстәкыйль аерып чыгарырга һәм әйтеп бирергә өйрәнә.

Уку эшчәнлеге төркемнәрдә оештырылып, укучының тыңлый, ишетә, үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга җиткерә алуы, янәшәсендәгеләрне кимсетмичә, үз фикерен яклый белүе коммуникатив (коммуникативные действия) гамәлләр формалаштыруга ярдәм итә.

Татар телен өйрәнгәндә, УМ кую, чишү юлларын билгеләү, аны чишү, үз эшенә контроль ясый һәм бәя бирә белү – бик кирәкле регулятив (регулятивные действия) гамәлләр.

Туган телне укыту процессында баланың мәгълүмат белән эшләү культурасы үсү, дәреслек белән нәтиҗәле эш, сүзлекләрдән, белешмәлекләрдән, башка төрле белем чыганакларыннан, мәсәлән, компьютердан файдалану, ысул аерып ала белү, эчтәлекне модельләштерү кебек күнекмәләргә ия булуы танып белү (познавательные действия) гамәлләре формалашуны дәлилли.

Татар теле дәресләрендә кулланылган һәр текст, җөмлә, халык педагогикасыннан алынган мисаллар - барысы да гомумкешелек кыйммәтләренә уңай мөнәсәбәт тәрбияләүгә юнәлтелгән әхлакый (личностные действия) гамәлләр.

Татар теле буенча гомуми белем бирү максатларына ирешү коммуникатив, лингвистик, этнокультура өлкәсенә караган компетенцияләр булдыру аша бара. Программада компетенцияләргә сәгатьләр санын бүлгәндә, коммуникатив компетенциягә сәгатьләр бүленеше аерым каралса да, линвгистик һәм этнокультура (этномәдәни) өлкәсенә караган компетенцияләрне берләштереп бирү максатка ярашлы дип табылды, чөнки лингвистик компетенция, ягъни татар теленең тармаклары буенча үзләштерергә тиешле төп теоретик мәгълүматлар халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләрен чагылдырган күнегүләр, халык авыз иҗаты үрнәкләре (мәкаль, әйтем Һ.б.) белән бәйләп бирелә.

***Коммуникатив компетенция***

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре (тыңлап аңлау,сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) үзләштерелә. Укучылар тыңланган яки укылган текстның темасын, төзелешен һәм төп фикерен, жанрын ачыклый, текст буенча әңгәмә үткәрә, үз фикерен дәлилли, телнең орфографик һәм орфоэпик, лексик, морфологик, синтаксик нормаларын саклап, телдән яки язмача эчтәлеген кыскача, тулы, сайлап алып җиткерә. Телнең әдәби нормаларын саклап, төрле темаларга диалогик һәм монологик сөйләм оештыра. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзи. Төрле типтагы язма эшләр, шул исәптән компьютер кулланып, диктант, изложение, сочинение, тестлар һ.б. эшләр башкара. Татар сөйләм этикеты нормаларын дөрес һәм урынлы куллана.

***Лингвистик компетенция***

Татар теленең тармаклары буенча үзләштерергә тиешле төп теоретик **мәгълүматлар:**

1. Татар теленең иҗтимагый-мәдәни роле; татар милли әдәби теле һәм аның төп орфографик, орфоэпик нормалары; телнең фонетик системасы һәм закончалыклары; иҗек, татар теленең иҗек калыплары; басым, интонация һәм аларның төрләре; орфография һәм орфоэпия.
2. Сүз, аның лексик мәгънәсе; сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләре; татар теленең сүзлек составы, аның ачык система тәшкил итүе; сүзләрне килеп чыгышы, кулланылыш даирәсе һәм активлыгы ягыннан төркемләү; фразеологик әйтелмәләр, аларның мәгънә үзенчәлекләре; лексикография, сүзлекләрнең төрләре.
3. Сүзләрнең мәгънәле кисәкләре, аларның төрләре, сүз ясалыш ысуллары.

4. Мөстәкыйль сүз төркемнәренең лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәренең грамматик үзенчәлекләре, сөйләмдә кулланылышлары.
5. Сүзтезмә һәм җөмлә, сүзләр һәм җөмләләр арасында бәйләнеш төрләре; җөмлә кисәкләре; җөмләләрне төркемләү принциплары; туры һәм кыек сөйләм; текст, аның төзелеше; татар телендә тыныш билгеләре.
6. Функциональ стильләр, аларның лексик-грамматик үзенчәлекләре; сөйләм культурасы.
7. Җөмләгә  синтаксик анализ һәм җөмләдәге сүзләргә фонетик, лексик, морфологик анализ ясау, сүзләрне төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерү.

***Этнокультура өлкәсенә караган компетенция***

Тел чаралары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләрен өйрәнү; тәкъдим ителгән текстлардан халык авыз иҗаты үрнәкләрен, тарихи лексиканы аеру, аларның төрләрен һәм мәгънәләрен өйрәнү.

**Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр**

8 нче сыйныфта татар теле предметын өйрәтү тел берәмлекләрен таный, аңлый, анализлый белү күнекмәләре белән бергә, сөйләм культурасын үстерүне, төрле типтагы мәгълүматны, сөйләм ситуациясенә карап, дөрес һәм төгәл итеп башкаларга җиткерә алуны, татар теленең әдәби һәм сөйләм этикеты нормаларын үтәүне дә бурыч итеп куя.

***Шәхси нәтиҗәләр:***

- баланың акыл, мөстәкыйль фикерләү эшчәнлеген активлаштыру;
- баланың үзен тәрбияләү, үзе белән идарә итү, үз фикерен яклый алу сәләтен үстерү;
- сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен аңлау;
- укучының үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләренә, әхлак нормаларына төшендерү.

***Предметны үзләштерү барышында ирешергә тиешле нәтиҗәләр:***

- телдән һәм язма сөйләм, диалог һәм монолог, аралашу ситуациясе, тел стильләре, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- төрле стиль һәм жанрдагы текстларны сәнгатьле итеп уку күнекмәләре булдыру;

- текстның эчтәлеген телдән яки язмача төгәл итеп, сайлап яки кыскача сөйләп бирү, текст буенча куелган сорауларга төгәл җавап бирү;
- бирелгән темага, куелган максатка ярашлы рәвештә, төрле ситуацияләрдән чыгып, тасвирлау (сыйфатлама) яки хикәяләү характерындагы текстларны телдән яки язмача әзерләү;
- текстның планын төзү яки эчтәлеген конспект, тезис рәвешендә язу;
- җөмләгә синтаксик анализ һәм җөмләдәге сүзләргә фонетик, лексик, морфологик анализ ясау, сүзләрне төзелеше һәм ясалышы ягыннан тикшерү;
- тормыш-көнкүреш, уку, иҗтимагый, мәдәни темаларга әңгәмә кору, үз фикерекңне яклап, әңгәмә-бәхәс формасында сөйләшү күнекмәләренә ия булу;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби нормаларын (орфографик, орфоэпик, лексик, грамматик, пунктацион) саклау һәм сөйләм этикеты нормаларын үтәү;

***Предметара нәтиҗәләр:***

- татар теленең башка фәннәрне өйрәнү һәм белем алу чарасы икәнен аңлау;
- татар телен әдәбият белән бәйләп, тел чараларының матур әдәбият әсәрләрендәге тәэсир көчен, сәнгатьлелеген булдырудагы ролен ачыклау;
- телне мәдәният белән бәйләп, татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- татар телен рус теле белән бәйләп, телләр һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә – рухи кыйммәтләргә ихтирам, башка милләт вәкилләренә карата түземле-ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;
- телне тарих, җәмгыять белеме фәннәре белән бәйләп, дөнья, кешелек җәмгыяте, анық үсеше турында күзаллау формалаштыру;
- телнең кеше һәм җәмгыять тормышында тоткан урынын аңларга ярдәм итү.

**Эш программасы статусы**

1) Программа разработана на основе следующих нормативно-правовых документов:
Конституция Российской Федерации;
2) Федеральный закон от 29 декабря 2012 г. № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (с изменениями и дополнениями);
3)Закон Российской Федерации от 25 октября 1991 г. № 1807-1 «О языках народов Российской Федерации» (с изменениями и дополнениями);
4) Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования (утвержденный приказом Министерства просвещения Российской Федерации от 31 мая 2021 г. № 287);
5) Примерная основная образовательная программа основного общего образования (одобренная решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол № 1/22 от 18 марта 2022 г.);
6) Примерная программа (одобрена решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию, протокол № 2/220 от 2 июня 2020 г.);
7) Концепция преподавания родных языков народов России (утверждена решением коллегии министерства просвещения РФ от 1 октября 2019 года № ПК-3ВН).

**Дәреслек**

”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011нче ел.
4.Р.К.Сәгъдиева, Г.И.Хәйруллина , Татар теле, 8 нче сыйныф. Рус телендә белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы, Казан, “Мәгариф-Вакыт” Та нәшрияты, 2017 нче ел.

**Укыту фәненең уку планында тоткан урыны программада күрсәтелгәнчә: елга - 34 сәг; атнага: 1 сәгать**

**Эш программасы структурасы.**

Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләр, белем һәм күнекмәләр, укытуның гомуми, шәхси, метапредмет нәтиҗәләрен үз эченә алган программаның эчтәлегеннән**.**

**8нче класс укучыларның белем күнекмәләре.**

1. Алдагы сыйныфларда алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту.

**Гади җөмлә синтаксисы һәм пунктуациясе:**

1. Сүзтезмәләргә, гади җөмләләргә синтаксик анализ ясый белү.
2. Җөмләнең баш кисәкләрен, иярчен кисәкләрен табып , аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүен әйтү .Ия белән хәбәр янында сызык кую очракларын белү.
3. Сүзтезмәне җөмләдән аера белү. Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
4. Аерымланган җөмлә кисәкләре, эндәш һәм кереш сүзләр кергән җөмләләр төзү. Аерымланган хәлләр, аерымланган аныклагычлар, эндәш, кереш сүзләр янында тыныш билгеләрен куя белү.
5. Туры һәм кыек сөйләмне дөрес куллану, алар кергән җөмләләр төзү.Диалог, туры һәм кыек сөйләм янында тыныш билгеләрен куя белү.
6. Җөмләнең әйтү максаты ягыннан төрен, интонация, логик басым һәм сүз тәртибен белү. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен куя белү.
7. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында тыныш билгеләрен дөрес куллану.

**Сөйләм эшчәнлеге:**
1. Эш кәгазьләреннән әдәби әсәр героена адреслаңган хат язу, әдәби геройларга характеристика язарга өйрәнү.
2. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе. Хикәяләр язу.
3. Грамматик биремле контроль диктантлар, төрле типтагы диктантлар язу (85-110сүз).
4.Сочинение элементлары булган изложениеләр язу (270-350, 125-135)
5. Татар телендәге сүз тәртибе үзенчәлекләрен чагылдырган кыска текстларны тәрҗемә итү күнегүләре үтәү.
6. Бирелгән план буенча сочинениеләр язу (2-2,5 бит)

**Программа материалының эчтәлеге.**

| № | Төп темалар | Темага караган төп төшенчәләр. |
|---|---|---|
| 1 | 5-7 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | Сүз ясалышы, сүз төзелеше, сүз төркемнәре, фигыль, фигыль юнәлешләре, җөмләдә сүзләр тәртибе; |
| 2 | Синтаксис турында төшенчә | Синтаксис турында төшенчә, синтаксик берәмлекләр; |
| 3 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Сүзтезмә. | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше, тезүле бәйләнеш, ияртүле бәйләнеш, сүзтезмә, рус һәм татар телләрендә сүзләр бәйләнеше; |
| 4 | Сүз тәртибе. | Уңай һәм кире сүз тәртибе. Татар һәм рус телләрендә сүзләрнең урнашу тәртибе үзенчәлекләре. |
| 5 | Гади җөмлә төрләре. | Җөмлә турында кабатлау. |
| 6 | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. | Хикәя, сорау, боеру , тойгылы җөмләләр, алар янында тыныш билгеләре. |
| 7 | Җөмлә кисәкләре. Гомуми мәгълүмат. | Җөмлә кисәкләре турында мәгълүмат |
| 8 | Баш кисәкләр | Җөмлә кисәкләре, ия һәм аның белдерелүе, хәбәр һәм аның белдерелүе, кушма хәбәр һәм аның белдерелүе, ия белән хәбәр арасында сызык; |
| 9 | Җөмләнең иярчен кисәкләре | Аергыч һәм аның белдерелүе, аергыч белән аерылмыш арасында бәйләнеш;<br>тәмамлык һәм аның белдерелүе,туры һәм кыек тәмамлыклар;<br>хәл һәм аның төрләре: урын хәле, вакыт хәле, рәвеш хәле, күләм хәле, сәбәп хәле, максат хәле, |

| | | |
|---|---|---|
| | | шарт хәл, кире хәл;<br>аерымланган хәлләр һәм алар янында тыныш билгеләре, төрле хәлләрнең аерымлануы;<br>аныклагыч; аерымланган аныклагычлар, алар янында тыныш билгеләре, |
| 10 | Җөмләнең модаль кисәкләре | Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре; кереш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре; кереш җөмләләр һәм алар янында тыныш билгеләре; |
| 11 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | Тиңдәш кисәкләр, алар янында бәйләүче чаралар, тиңдәш кисәкләр һәм янында тыныш билгеләре; тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр; |
| 12 | Модаль кисәкләр | Сүзләрнең уңай һәм кире тәртибе, логик басым; |
| 13 | Бер составлы җөмләләр | Бер составлы җөмләләр: исем җөмлә, фигыль җөмлә, сүз җөмлә; |
| 14 | Тулы һәм ким җөмләләр. | Тулы һәм ким җөмләләр турында төшенчә; |
| 15 | Раслау һәм инкарь җөмләләр | Раслау һәм инкарь җөмләләр, раслау һәм инкарь җөмләләрнең кулланлышы; |

## Укыту – методик комплекты

1. ”Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” 1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011нче ел

2. 4.Р.К.Сәгъдиева, Г.И.Хәйруллина , Татар теле, 8 нче сыйныф. Рус телендә белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы, Казан, “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017 нче ел.

3. Татар теле укытучылары өчен методик кулланма (Пермь краеның гомуми белем бирү оешмаларының 1-9 нчы сыйныфлары өчен), 2015 нче ел.

4. “Диктантлар җыентыгы”(5-11 нче сыйныфлар өчен) З.Н.Хәбибуллина, Г.Ш.Нәбиуллина. Казан ”Мәгариф” нәшрияты, 2004нче ел.

Календарь-тематик план

| № | Вакыты | Дәреснең темасы | Сәгать саны | Метод һәм алымнар | Көтелгән нәтиҗә | | | Өй эше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Махсус белем | Махсус күнекмә | Гомумуку күнекмәләре | |
| 1 | | Кереш. 5-7 нче сыйныфларда өйрәннәрне кабатлау. | 1 | Укытучы әңгәмәсе, дәфтәр башлату, үткәннәрне кабатлау, күнегүләр эшләү, дәрескә йомгак. | 7нче сыйныфта үткәннәрне искә төшерү. Фонетиканы кабатлау, сүзгә фонетик анализ ясау | Фонетиканы классификацияләү үзенчәлеген гомумиләште реп кабатлау. | Фонетик анализ ясый белү | 5нче күнегүне язып эшләргә |
| 2 | | Контроль күчереп язу | 1 | Текст белән танышу, аңлашылма ган сүзләрне аңлату, тәрбияви момент, язу, дәрескә йомгак. | Үткәннәрне гомумиләште реп кабатлау<br>. | Җөмлә төрләрен дөрес билгеләп, тыныш билгесен дөрес кую. | Мөстәкыйль эшли белү күнекмәсен үстерү | Үткәннәрне кабатларга |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | | Синтаксис. Сүз һәм җөмлә | 1 | Хаталар җибәрелгән очраклар белән бәйле кагыйдәләрне искә төшерү, тактадагы мисалларны тикшерү, нәтиҗә чыгару, төркемләп эшләү, күнегүләр эшләү, дәрескә йомгак. | Синтаксис турында төшенчә. *Сүз, сүзтезмә, җөмлә* төшенчәлә рен формалаштыру. Сүз турында белемнәрне тирәнәйтү һәм системалаш тыру. | Дөрес итеп җөмләләр төзи белү, кушымчаларны дөрес ялгап, җөмләләрне оештыру | Яңа төшенчәләрнең күләмен билгеләү һәм модельләштерә белү. | 41нче күнегүне язып эшләргә |
| 4 | | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Тезүле бәйләнеш. Тиңдәш кисәкләр | 1 | Модельне уку, кагыйдә чыгару, тактада эшләү, күнегүләр эшләү | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше нең ике төре белән танышу, тезүле бәйләнеш турында төшенчә формалаштыру | Тезүле һәм ияртүле бәйләнешләрне тану, аеру. | Модель төзи белү күнекмәсен үстерү | 47 нче күнегүне язып эшләргә |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | | Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре, гомумиләштерүче сүзләр | 1 | Үзбашка эш, күнегүләр эшләү, группалап эш, “Кем тизрәк?” уены, дәрескә йомгак. | Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгесенең дөрес куелышын өйрәнү | Тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләрен дөрес кую. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләрне куллана белү | Тексттан мәгълүмат алу техникасын камилләштерү | **372, 377 нче күнегүләрне язып эшләргә** |
| 6 | | Ияртүле бәйләнешнең грамматик чаралары | 1 | Китап белән эш, күнегүләр эш, тикшерү, дәрескә йомгак | Ияртүле бәйләнешнең грамматик чараларын аңлату | Ияртүле бәйләнешкә кергән сүзләрне дөрес билгели белү | Төркемнәрдә ярдәмләшеп эшли белү күнекмәсен үстерү | Бирелгән җөмләләрдәге сүзләрнең бәйләүче чараларын язарга |
| 7 | | Сүзтезмә | 1 | Тактада эшләү, парлашып эшләү, күнегүләр өстендә ныгыту, дәрескә йомгак | Сүзтезмәләрне аерырга өйрәнү | Сүзтезмә һәм тезмә сүз төшенчәләрен аеру. Сүзтезмәгә синтаксик анализ ясый белү | Укуга уңай караш тәрбияләү | 71 нче күнегүне язып эшләргә |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | | Контроль күчереп язу | 1 | Укытучы әңгәмәсе, сорау-җавап, фикер алышу, план төзү, караламада язу, тикшерү, дәрескә йомгак. | | язу күнекмәсен үстерү | Грамматик нормаларны үтәп язу күнекмәсен үстерү | Үтелгәннәр буенча 10-12 сораудан торган тестлы биремнәр әзерләргә. |
| 9 | | Җөмлә кисәкләре. Җөмләнең баш кисәкләре | 1 | Җөмлә кисәкләренә нәрсәләр керүен искә төшерү, тест эшләү, баш кисәкләрне искә төшерү, күнегүләр өстендә ныгыту, дәрескә йомгак | Җөмләнең баш кисәкләре турында тулырак төшенчә бирү. | Ия һәм хәбәрнең кагыйдәләрен чыгару һәм әйтә белү. Ия, гади һәм тезмә ия | Чагыштырып нәтиҗәләр ясый белү. | Ирекле рәвештә текст алып, баш кисәкләрнең астына сызып килергә |
| 10 | | Исем хәбәр һәм фигыль хәбәр. | 1 | Укытучы әңгәмәсе, китап белән эш, күнегүләр эш, дәрескә йомгак | Хәбәрнең ике төре – исем һәм фигыль хәбәрләр турында төшенчә формалаштыру | Төзелешләре буенча исем, фигыль хәбәрләрнең гади, тезмә, кушма төрләрен белү, аера белү. | Гомумиләш терү күнекмәсен үстерү | 99 нчы күнегүне язып эшләргә, таблицаны өйрәнергә |
| 11 | | Ия белән хәбәрнең җөмләдәге урыны, сызык куйю очраклары | 1 | Әңгәмә, сорау-җавап, җөмләләр язу, кагыйдә дәфтәрдә | Ия белән хәбәрнең уңай һәм кире урнашу тәртибе турында | Инверсия күренешен таный белү. | Алдагы белемнәргә таянып, фикерне үстерү. | 103-104 нче күнегүләрне язып эшләргә |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | эшләү, күнегүләр эшләү, үзбашка эш, дәрескә йомгак. | төшенчә бирү. | | | |
| 12 | | Гади һәм кушма җөмлә | 1 | Язуны дәвам итү, эшне тикшерү, акка күчерү, дәрескә йомгак | Текст буенча мөстәкыйль план төзү | Үзең төзегән планга таянып, текстны логик эзлеклелектә бирү | Иҗади фикерләү сәләтен камилләштерү | Җөмләләр уйлап язарга |
| 13 | | Җөмләнең иярчен кисәкләре, аларның җөмләдәге урыннары | 1 | Укытучы әңгәмәсе, китап белән эш, тактада эшләү, күнегүләр өстендә эш, дәрескә йомгак | Җөмләнең ике төре – гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә формалаштыру | Гади һәм кушма җөмләләрне аера белү. | Гомумиләш терү күнекмәсен үстерү | “Беренче карның хыялы” дигән темага хикәя язарга |
| 14 | | Аергычның аерылмышы белән бәйләнеше | 1 | Әңгәмә, сорау-җавап, җөмләләр язу, кагыйдә чыгару, күнегүләр эшләү, дәрескә йомгак. | Җөмләнең иярчен кисәкләре, аларның урыннары турында белгәннәрне актуальләш терү | Җөмләнең иярчен кисәкләрен саный белү. | Уңай мотивация тудыру | 122 нче күнегүне язып эшләргә |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | | Тәмамлык һәм анық белдерелүе. Туры һәм кыек тәмамлыклар | 1 | Сорауларга җавап бирү, нәтиҗә ясау, күнегүләр эшләү, үзбашка эш, дәрескә йомгак. | Аергычның аерылмышы белән бәйләнешен ачыклау | Аергычның аерылмышына 2 төрле чара белән бәйләнүен күрсәтә белү | Танып белү активлыгын үстерү | “Минем дустым” темасына сочинение-сыйфатлама язарга |
| 16 | | Контроль күчереп язу | 1 | Дәреслек, “Диктантлар җыентыгы” китабыннан текст белән танышу, аңлашылмаган сүзләрне аңлату, тәрбияви момент, язу, тикшерү, дәрескә йомгак. | Ел буена үткәннәрне тикшерү һәм ныгыту | Гади җөмлә синтаксисына караган төп төшенчәләрне актуальләштерү | Үз-үзеңне дөрес бәяләү күнекмәсен камилләштерү | Кагыйдәләрне, үткәннәрне кабатлап чыгарга |
| 17 | | Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау | 1 | Ике команда арасында ярыш үткәрү, күнегүләр эшләү, уку елына нәтиҗә ясау, дәрескә йомгак. | Гади җөмлә синтаксисына караган төп төшенчәләрне актуальләштерү һәм тирәнәйтү | Гади җөмләгә синтаксик анализ ясый белү | Белемнәрне системалаштыру | Каникулда кагыйдә дәфтәрдә язылганнарны кабатларга, газета-журналлар укырга |